| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 13 декабря 2013 года г. Казань № 3-13/э

***“Татарстан Республикасы җирендә челтәри оешмаларның челтәре буенча электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен бердәм (котел) тарифларын билгеләү” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 24.12.2012 №3-18/э карарына үзгәртүләр кертү турында***

“Электр энергетикасы турында” 26.03.2003 №35-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Электроэнергетика өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) билгеләү” 29.12.2011 №1178 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, һәм 24.10.2013 №953 “Электроэнергетика һәм тарифлар өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) билгеләү нигезләренә үзгәртүләр кертү турында”, “Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә бәяләрне һәм җайга салынучы тарифларны билгеләү өлкәсендә методик киңәшләрне раслау хакында” 06.08.2004 №20-э/2 Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең боерыгы һәм “Тулай керемне озак сроклы индексацияләү ысулын кулланып, электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен тарифларны исәпләүдә методик киңәшләрне раслау хакында” 17.02.2012 №98-э, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы җирендә челтәри оешмаларның челтәре буенча электр энергиясен тапшыру хезмәте өчен бердәм (котел) тарифларын билгеләү” (Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 03.06.2013 №3-3/э карары редакциясендә) Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты 24.12.2012 №3-18/э карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 кушымтаны әлеге карарның кушымтасына таянып яңа редакциядә язырга.

2. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көнне гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына кушымта
13 декабрь 2013 ел № 3-13/э

Озак сроклы тәртипкә салу параметырлары
ААЖ “Сетевая компания” 2012-2014 еллар өчен.

(ӨБС исәпкә алынмаган)

| Татарстан Республикасы челтәри оешманың исеме | Ел | Контролләнгән чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Контролләнгән чыгымнарның файдалылык индексы | Контролләнгән чыгымнарның активларның санына карап сыгылмалык коэффициенты | Электр энергиясенең технологик чыгымнар (югалтулар) күләме | Сатылган товарның ышанычлылыгы (хезмәт) | Сатылган товарның сыйфаты (хезмәт) | Челтәргә технологик тоташтыруның сыйфаты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | млн.сум | % | % | % | | | |
| ААЖ «Сетевая компания» | 2012 | 7355,08 | 1 | 75 | 9,51 | 0,03702 | 1,0102 | х |
| | 2013 | х | 1 | 75 | 8,89 | 0,0365 | 0,99505 | х |
| | 2014 | х | 1 | 75 | 8,26 | 0,0359 | 0,98012 | 1,00727 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге